СОВЕТ
УТАР-АТЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
*РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН*
ул.Кооперативная, д. 22, с. Утар-Аты,
Арский муниципальный район, 422017

*ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ*
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УТАР-АТЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Кооператив урамы, 22 йорт, Утар-Аты авылы,
Арча муниципаль районы, 422017

Тел. (84366)50-3-31, факс (84366)50-4-22. E-mail: Utat.Ars@tatar.ru

**Утар-Аты авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**28 сентябрь 2018 ел.** **№ 67**

## Гражданнарның үзара салымын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Арча муниципаль районының Утар-Аты авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, №67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьялары, «җирле референдум турында» 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар-Аты авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы, Утар-Аты авыл җирлеге башкарма комитетының 2018 елның 24 сентябрендәге 12 номерлы "Референдум үткәрүне оештыру турында" карары нигезендә Утар-Аты авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. 2018 елның 18 ноябренә Утар Аты авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне раславга:
"2019 елда үзара салым кертүгә Утар Аты авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән 500 сум күләмендә, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш, сез риза буласызмы?:

1. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге
-торак пунктларда вак таш сатып алу, җирле әһәмияттәге юл-урам челтәренең машиналар йөрү өлешен тигезләү һәм төзү;:
Утар Аты авылы:9май, Совет урамы, Комсомол урамы, Мәктәп урамы, Кооператив урамы; Субаш-Аты авылы: Кооператив урамы, Яңа урамы, 9май урамы, Тарлау; Орнашбаш авылы: Мичурин урамы, Зеленая урамы, Механизаторлар урамы, Тукай урамы, клуб, Яшьләр урамы, Комсомол урамы; Югары Аты авылы: Кооператив урамы, Комсомол урамы, Мәктәп урамы; Иске Җөлбә авылы: Үзәк урамы, 9 Май урамы; Кушлавыч авылы: 8 Март;
- Орнашбаш авылындагы Молодежная – Комсомольская урамнары киселешендәге «Орнаш " елгасы аша күперне ремонтлау

2. Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- Орнашбаш т. п. Тукай урамы буенча «Орнаш» елгасы аша җәяүлеләр кичүен ремонтлау һәм материаллар сатып алу эшләрен тәмамлау;
- Субаш-Аты, Орнашбаш авылларында чишмә төзекләндерү һәм материал сатып алу;;

3. Җирлек торак пунктларында беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:
-Утар Аты, Орнашбаш авылларында янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру (һәр торак пунктка берәр);
-Утар Аты, Орнашбаш, Югары Аты, Субаш Аты, Иске Җөлбә, Кушлавыч авылларында (һәр торак пунктның берәрсе) янгын мотопомпалары сатып алу.

4. Күмү урыннарын карап тоту
- Иске Җөлбә, Кушлавыч авыллары зиратлары коймаларын төзекләндерү һәм материал алу;;
- Кушлавыч авылы зиратына чүп җыю өчен контейнер сатып алу;

5. Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:
- Субаш-Аты авылында материал сатып алу һәм кое ремонтлау эшләре үткәрү ;
Экономияләнгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча авыл җирлеге башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.
ЮК ӘЛЕ".

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга. http:pravo.tatarstan.ru) гражданнар күплэп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында мәгълүмат:
ТР, Арча районы, Утар Аты авылы, Кооператив урамы, 22 йорт; ТР, Арча районы, Орнашбаш авылы, Яшьләр урамы, 6 йорт; ТР, Арча районы, Кушлавыч авылы, Тукай урамы, 1

4 . Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Утар Аты авыл җирлеге башлыгы
авыл җирлеге башлыгы И. И. Гайнуллин

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «УТАР-АТЫНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» СОВЕТ УТАР-АТЫНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН 1609012621